ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ФЕДОТОВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ФЕДОТОВКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 11 ноябре № 7

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Кузьминовка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Кузьминка торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 23 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Кузьминовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан; сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан; Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарының тол хатыннарыннан; көндезге бүлектә укучы студентлардан, срочный хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2025 елда 300 (Өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункты территориясен төзекләндерү (МТЗ-82.1 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү(ягулык-майлау материаллары сатып алу); тракторчы

хезмәтләре өчен килешү буенча түләү ( территорияне коры-сары һәм чүп үләннәреннән чаптыру, кардан чистарту, полосаларны минеральләштерү һәм сөрү һәм башка төр эшләр)

2) торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын тозу, ремонтлау, карап тоту( Мәктәп, Кооператив, Заречная урамнарындагы вак таш түшәлгән юллардагы чокырларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм ташу)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Федотовка авылы, Совет ур., 6 й., Совет ур., 8 й. (мәдәният йорты бинасы), Кузьминовка авылы, Кооператив ур., 10 й. (мәдәният йорты бинасы), Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Федотовка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы В.И.Павлова